**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от_________________ ПР-243 14.11.2024 № ___________

Актаныш муниципаль районы милкендәге, кече
һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан
арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне сатып
алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда,
сатып алу өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган булган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында" һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Актаныш муниципаль районы милкендәге, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган мөлкәтне өстенлекле хокукны гамәлгә ашырып сатып алганда кичектереп түләү срогы күчемсез милек өчен биш ел һәм күчемле милек өчен өч ел тәшкил итә.

2. Сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер тапкыр яисә өлешләп түләү), шулай ук арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукы кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районының «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Ильясов